| | |
|---|---|
| СОВЕТ СМАИЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СМӘЕЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25 декабрь 2025 ел № 16

**Балтач муниципаль районы Смәел авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Смәел авыл җирлеге башлыгының, Смәел авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең хезмәтенә түләү тәртибе турында»гы 2018 елның 25 декабрендәге 95 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (2023 елның 17 март 66 нчы номерлы, 2024 елның 22 июле 100нче номерлы, 2024 елның 30 нчы октябре 104 нче номерлы, 2025 елның 14 нче май 125 нче номерлы үзгәрешләр белән)**

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 25 нче ноябрь 994 нче номерлы карары, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең контроль-хисап палатасы рәисенә, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәре, айлык һәм башка өстәмә түләүләр һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе күләмнәре турында» Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2018 елның 28 апрелендәге 127 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Советының 2025 елның 17 нче декабре 26 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Смәел авыл җирлеге Уставы нигезендә, Балтач муниципаль районының Смәел авыл җирлеге Советы карар бирә:

1.«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Смәел авыл җирлеге башлыгының, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль

районының Смәел авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең (алга таба - Карар) хезмәтенә түләү тәртибе турында» 2018 елның 25 декабрендәге 95 нче номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Смәел авыл җирлеге Советы карарына (17.03.2023. №66; 22.07.2024. №100; 30.10.2024. №104, 14.05.2025 № 125 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 2 пунктындагы «15 389» санын «16 928» санына алмаштырырга;

1.2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Смәел авыл җирлеге башлыгы хезмәтенә түләү Тәртибенең ( 1нче кушымта) 1 пунктында «21 091» санын “23 201» санына алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (www.baltasi.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар имза куйган көннән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземә калдырам.

Смәел авыл җирлеге башлыгы Р.Г.Йосыпов